Яңа йортның ишегенә
Элепләр куйдык дага.
Тел-тешләрдән, кайгылардан,
Сакласын диеп Ходa(й).
Яңа йортлар калкып торсын,
Шәһәрләрдә, авылда.
Туган илләр башлана
Туган нигез ташыннан.

*Кушымта.*

Туган йортның диварына
Туган-тумача тулсын.
Кояш кебек елмаешып,
Балалар йөгереп йөрсен.
Гөлләр үскән нигезләрдә
Йөгереп йөрсен балалар.
Яңа йортка бәхет теләп
Имин торсын дөньялар!

*Кушымта.*

## ГАИ ҖЫРЫ

Айрат Нәбиев көе
(Айдар Галимов репертуарыннан)

Юлда тора егетләр —
Чып-чын сөлек кебекләр.
ГИБДД хезмәте-
Төптән белә эш рәтен.

*Кушымта*:
ГАИ-абый таяк яный,
Шаяртып һәм яратып.
Эшләре баштан ашса да
Хәл сораша туктатып.

Хәер биреп юлга чыксам,
Юлым уңа, эш бара.
Борын чөймә, ГАИ-абый,
Туктатырга тап чара.

*Кушымта.*

Эх, тала,тала,тала,
Таладыр бит беләгең.
Юлда тәртип булсын диеп
Янадыр бит йөрәгең.

Өшеп туңып, тирләп-пешеп,
Җиде юллар чатында,
Юлчыга иминлек теләп,
Юл хуҗалары тора.

*Кушымта.*

Көнен-төнен, кич һәм иртән
Алар тәртип сагында.
Җаннар атып, рәхмәт әйтеп
Җырлыйк ГАИ хакында.

*Кушымта.*

Туктатып...
Яратып...
Кирәк икән протоколын
Язып бирә җан атып!

*Кушымта.*

## ДУСЛЫК ҖЫРЫ

Айрат Нәбиев көе
(Айдар Галимов репертуарыннан)

Таулар очып, елга кичеп
Җир чигенә барырмын.
Назга сусаган дусларны
Кочагыма алырмын.

*Кушымта:*
Чын дуслыкка киртә түгел
Биек Урал, Каф-таулар.
Дуслыкларны аералмый
Киң һәм тирән елгалар.
Берләштерә, дуслаштыра
Агыйдел, Сөн елгалар,
Җырлап кына узсын гомер,
Җырлап барсын дөньялар.

Дуслар булсын һәр җирдә дә,
Казанда һәм Уфада,
Самарларда, Чиләбедә
Мәскәүдә, Сарытауда.